ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТЕЛӘКӘЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423749, Иске Теләкәй авылы,
Үзәк ур.,87 нче йорт.
Тел. 3-44-59

СОВЕТ ТЛЯКЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423749, село Старое Тлякеево,
ул. Центральная, дом 87.
Тел. 3-44-59
Эл.адрес: telak-akt@yandex.ru

---

КАРАР
19 декабрь 2023 ел

РЕШЕНИЕ
№ 20

**«Җир салымы турында» 2023 елның 14 декабрендәге 17 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге (икенче өлеш), “Теләкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Актаныш муниципаль районының Теләкәй авыл җирлеге карар итте:

1. «Җир салымы турында» 2023 елның 14 декабрендәге 17 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 п.3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында” 2022 елның 21 сентябрендәге № 647 Указы (алга таба - мобилизация буенча гражданнарны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (ирләрен, балигъ булмаган балаларын һәм балаларын 23 яшькә кадәрге, мәгариф оешмаларында көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балаларын) нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары;

1.2. п.3 түбәндәге эчтәлекле 10, 11, 12, 13, 14 абзацлар өстәргә:

-алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның ата-аналарын;

- махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының (ире, балигъ булмаган балалары һәм 23 яшькә кадәрге, мәгариф оешмаларында көндезге формада укучы балаларның);

-алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләренең ата-аналары.

- махсус хәрби операциядә катнашучылар, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булучылар;

- махсус хәрби операциядә (ире (хатыны), балигъ булмаган балалары, ата-аналары һәм хезмәткә сәләтсез башка иждивенецлар) катнашучыларның гаилә әгъзаларын)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Теләкәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе Х.Н.Гатауллин